ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**08.11.2019** **1653**

2020 нче елга Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләре эшчәнлеген финанслау нормативларын раслау турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 нче елның 29 нчы декабрендәге 273-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Законы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 нче елның 6 нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында» 2019 нчы елның 2 нче июлендәге 546 нчы номерлы карары нигезендә, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2020 нче елга түбәндәгеләрне расларга:

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында тәрбияләнүчеләрне карап тоту һәм карау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарын, әлеге карарның 1 нче кушымтасындагыча;

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләрендә балаларны караган һәм тәрбияләгән өчен ата-аналар түләвенең күләмен, әлеге карарның 2 нче кушымтасындагыча;

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында 2020 нче елның 1 нче гыйнварына кадәр кертелгән тәрбияләнүчеләрне карап тоту һәм караган өчен ата-ана түләвенең көчеш чоры коэффициентларына төзәтмәләр кертеп мәгариф учреждениеләре исемлеген, әлеге карарның 3 нче кушымтасындагыча;

ата-аналар түләве күләмен оештыру буенча бәя нормативлары коэффициентларына төзәтү 2020 нче елның 1 нче гыйнварына кадәр белем бирү оешмаларына кертелгән балага, мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләрендә балаларны караган һәм тәрбияләгән

өчен ата-аналар түләвенең күләменә карата төзәтү коэффициенты: 2 айдан 3 яшькә кадәрге балалар өчен бертигез кабул ителә - 0,87, 3 яшьтән алып белем бирү мөнәсәбәтләре туктатылганчыга кадәрге балалар өчен – 0,89.

2. Алабуга муниципаль районы финанс-бюджет палатасына тәэмин итәргә: әлеге карарның 1 пункты белән расланган мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрен финанслау нормативлары нигезендә мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрен финанслау.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2020 нче елның 1 нче гыйнварыннан барлыкка килә торган хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче Р.М. Нуриев